**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» июнь 2019 ел № 131

Бирючевка, Кәкре Елга, Мәсгут, Микулино, Сукаеш, Чемодурово авыл җирлекләре чикләрендә Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру проектын һәм межалау проектын әзерләү турында «Азнакайнефть» идарәсе (2018 ел) мәйданнарын төзекләндерү объектларын киңәйтү»

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы нигезендә, «Татнефть» ҖАҖ «Азнакайнефть» идарәсе тәкъдимен карап, Азнакай муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә карар бирәм:

1. «Татнефть» ГАҖ «Азнакайнефть» идарәсенең территорияне планлаштыру проектын һәм «Азнакайнефть» идарәсе мәйданнарын төзекләндерү объектларын киңәйтү» объекты өчен Азнакай муниципаль районының Бирючевка, Кәкре Елга, Мәсгут, Микулино, Сукаеш, Чемодурово авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан территорияне межалау проектын үз акчалары хисабына әзерләү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Территорияләрне планлаштыру буенча документларны әзерләү тәртибе, әзерләү сроклары һәм эчтәлеге турында физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау өчен Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлегенә җибәрергә. Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү вакыты һәм эчтәлеге турындагы тәкъдимнәрне карагандa әлеге тәкъдимнәрне керткән физик һәм юридик затларны чакыруны тәэмин итәргә кирәк.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары Р. Р. Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов